ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, ,
423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а
йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**03 февраль 2023 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2022 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Ак-Юл торак пунктының халык җыенының 1 санлы карары,

2022 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Тарлау торак пунктының халык җыенының 2 санлы карары,

2022 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Екатериновка торак пунктының халык җыенының 3 санлы карары,

2022 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Яссы-Тугай торак пунктының халык җыенының 4 санлы карары,

2022 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Димтамак торак пунктының халык җыенының 5 санлы карары,

2022 елның 22 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Алабакүл торак пунктының халык җыенының 6 санлы карары,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан бирле үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы: Җ.Ә.Хөснетдинов

2023 елның 03 февралендәге
Димтамак авыл җирлеге башкарма
комитететының 4 санлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, бала чактан инвалидлар, I һәм II төркем инвалидлар, Россия Федераөиясе кораллы көчләренә чакырылучылардан тыш, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 25 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

2023 елның 03 февралендәге
Димтамак авыл җирлеге башкарма
комитететының 4 санлы карарына
2 кушымта

Димтамак авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта____________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә _________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО 92654440

Билгеләнгән түләү **2023 ел өчен Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы.**

Җитәкче ______________________________________________________
П.У. (имза) (имзаны раслау)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Димтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(*муниципаль берәмлек исеме)*
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны ___________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*